Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы
карары

2024 елның 16 декабре № 54/2

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
"Татар Ялтаны авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 84 - 86 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының « Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1 статьяның 2 пунктында «кыскартылган исеме - Татар Ялтаны авыл җирлеге» сүзләрен өстәргә;
1.2. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;
1.3. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7 статья. Җирлекнең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы
Җирлектә муниципальара хезмәттәшлек федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;
1.4. 11 статьяның 7 пунктында «Муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны уздыру буенча сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны уздыру буенча сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
1.5. 12 статьяның 3 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны уздыру буенча сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
1.6. 13 статьяның 8 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны уздыру буенча сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
1.7. 30 статьяның 1 пунктында «Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны уздыру буенча сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;
1.8. 31 статьяның 1 пунктындагы 12 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;
1.9. 38 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:
«10.1) аларга чит ил агенты статусы алу;»;
1.10. 44 статьяның 4 пунктында «(Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 47 статьяда:
1 пунктның 5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«- «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала;»;
1 пунктның 7 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру өлкәсендәге муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;
3 пунктта 1-5 пунктчаларын түбәндәге эчтәлекле 1-3 пунктчаларына алмаштырырга:
«1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;
2) Җирлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;
3) әлеге Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.»;
1.12. 55 статьяга түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:
«Вазыйфаи затларга, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләү туктатылганда, файдаланылмаган барлык отпусклар өчен акчалата компенсация түләнә.»;
1.13. 56 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
1.14. 58 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен, Россия Федерациясе субъекты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә җаваплы булалар.»;
1.15. 69 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:
«69 статья. «Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе»
1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючы булып тора торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
2. Муниципаль норматив хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне игълан итүне гамәлгә ашыру:
1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru; Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан 17.12.2013 ел, № ФС77-60244 ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) яисә «Чистай хәбәрләре» газетасында (Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 30.11.2007 ел, № ФС7-4785 ПИ теркәлү турында таныклыгы) рәсми бастырып чыгару;
2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Җирлекнең рәсми сайтында https://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштыру;
3) чикләнмәгән затлар даирәсе өчен мөмкин булган урыннарда урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру.
3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә түбәндәге адреслар буенча тоташу пунктлары эшли: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Ялтаны авылы.
4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр аларны имзалаган көннән алып 10 эш көне эчендә, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан

яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, халыкка игълан ителә.

5. Салымнар һәм җыемнар турында җирлек Советының норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар имза салынган көннән үз көченә керә, әгәр актның үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса.».

1.16. 72 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары Җирлекләрне муниципаль милектәге, территориаль челтәр оешмасы яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасы системасындагы электр челтәре хуҗалыгы объектларын, Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарның 1.14 пунктчасы 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Р.Р. Гарифуллин